# КАРАР

19 сентябрь 2024 ел № 25 Урыссу штб

## Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссияләр тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турындагы карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетына административ комиссияләр тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турындагы карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.1. Билгеләнгән вакытта бюджетка түләнмәгән түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч) түләнүгә өметсез дип түбәндәге очракта танылa:

1) административ штраф түләүче физик затның Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә аны вафат булган дип игълан ителүе;

2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында»гы 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә гражданның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә ул азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;

3) оешманы - җирле бюджетка түләүләрне түләүчене оешманың мөлкәте җитмәгәнлектән һәм (яисә) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә аны юкка чыгару мөмкин булмаганга күрә түләнмәгән административ штрафны түләүче тарафыннан бетерү;

4) «Башкару эшчәнлеге турында»гы 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ санлы

Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктында каралган нигезләмә буенча башкарма документны түләтүчегә кайтару турында суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма производствоны тәмамлау турында һәм башкарма документны түләтүчегә кайтару хакында карар чыгару, әгәр җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч биш елдан артык узган булса;

5) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм "Башкару эшчәнлеге турында"гы 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ санлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы, - Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда оешманың мөлкәте җитмәү һәм аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле, җирле бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә. Теркәү органының «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында»гы 2001 елның 08 августындагы 129-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләтүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбен торгызуга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин